**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“07” ноябрь 2025 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылы территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (территорияне чистарту- Комыргуҗа авылында үлән чаптыру; Комыргуҗа авылы паркы территориясендә газон чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).
- Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын төзү, ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү (Комыргуҗа авылында (Тукай урамына) юл салу өчен изелгән таш сатып алу (эш һәм хезмәт өчен түләү); Комыргуҗа авылы урам юлларын кардан чистарту.
- Ремонт, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны яхшырту (Комыргуҗа авылы зираты территориясен чистарту (үлән чабу, эш һәм хезмәт өчен түләү)).
- Урамдагы ачык яктырту челтәрләрен, трансформаторны һәм алар өчен бүтән подстанцияләрне, участокларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен таратылган башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту техникасы (лампаларны ремонтлау өчен материаллар сатып алу, лампаларны алыштыру, эш һәм хезмәт өчен түләү).

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Шарипов Ш.М.

СОВЕТ КОМЫРГУЖИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1610000733